КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 11 июль г.Казань № 574

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Азык-төлек продуктларын һәм ризыкларны илтеп бирү сервислары хезмәтләре (комиссиясе) өчен түләүгә бәйле булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чыгымнарын каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 25 апрель, 326 нчы карары белән расланган Азык-төлек продуктларын һәм ризыкларны илтеп бирү сервислары хезмәтләре (комиссиясе) өчен түләүгә бәйле булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чыгымнарын каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Азык-төлек продуктларын һәм ризыкларны илтеп бирү сервислары хезмәтләре (комиссиясе) өчен түләүгә бәйле булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чыгымнарын каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 25 апрель, 326 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 6 июнь, 467 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Азык-төлек продуктларын һәм ризыкларны

илтеп бирү сервислары хезмәтләре (комиссиясе) өчен түләүгә бәйле булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чыгымнарын каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 нче пунктта «30 июненә» сүзләрен «31 июленә» сүзләренә алыштырырга;

2.1 нче пунктның сигезенче абзацына «акцизлы товарлар» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу аркасында вәзгыять начараю шартларында аеруча зур дәрәҗәдә зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары белән исемлеге расланган яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу аркасында вәзгыять начараю шартларында аеруча зур дәрәҗәдә зыян күргән Россия икътисады тармакларында эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гариза бирүчеләрдән тыш),» сүзләрен өстәргә;

5.5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5. Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турындагы гарантия хаты субсидия алучы тарафыннан вәкаләтле оешмага хисап чоры тәмамланганнан соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча кәгазьдә тапшырыла. Субсидия алган көннән исәпләнә торган 30 календарь көн хисап чоры булып тора.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин